| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

18.12.2019 Казан шәһәре № 3-24/э

«Энерготранзит» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте белән «Челтәр компаниясе» ачык акционерлык җәмгыяте челтәр оешмалары арасында үзара исәп-хисап ясау өчен электр энергиясе тапшыру хезмәтләренә 2019-2023 елларга Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 14.12.2018 №3-12/э карары белән билгеләнгән дәвамлы хосусый тарифларга 2020 ел өчен төзәтмәләр кертү хакында

«Электр энергетикасы турында» 2003 елның 26 мартындагы 35-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Электр энергетикасында җайга салынулы бәяләр (тарифлар) өлкәсендә бәя кую турында» 2011 елның 29 декабрендәге 1178 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Ваклап сату (кулланучылар) базарында электр (җылылык) энергиясенә җайга салынулы тарифларны һәм бәяләрне исәпләү буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2004 елның 6 августындагы 20-э/2 номерлы һәм «Кирәкле тулай керемне озак сроклы индексацияләү алымын кулланып билгеләнә торган электр энергиясен тапшыру хезмәтләрен күрсәтүгә тарифлар исәпләү буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2012 елның 17 февралендәге 98-э номерлы боерыклары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турындагы нигезләмә нигезендә, 2020 елга Татарстан Республикасы территориясендә челтәр оешмалары арасында үзара исәп-хисаплар ясау өчен электр энергиясе тапшыру хезмәтләрен күрсәтүгә озак сроклы аерым тарифларга һәм җайга салынулы оешмаларның кирәкле тулай керемнәренә үзгәрешләр кертү максатларында Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Энерготранзит» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте белән «Челтәр компаниясе» ачык акционерлык җәмгыяте челтәр оешмалары арасында үзара исәп-хисаплар ясау өчен электр энергиясе тапшыру хезмәтләре күрсәтүгә 2019-2023 елларга аерым

тарифлар билгеләү турында» 14.12.2018 № 3-12/э карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә);

3 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә).

2. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 14.12.2018 № 3-12/э карарына 1 нче кушымта (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 18.12.2019 № 3-24/э карары редакциясендә)

## Татарстан Республикасы территориясендә челтәр оешмалары арасында үзара исәп-хисаплар ясау өчен җылылык энергиясен тапшыру хезмәтләренә 2019 елның 1 гыйнварыннан 2023 елның 31 декабренә кадәр календарь чорларына бүленгән аерым тарифлар

| № п/п | Челтәр оешмаларының аталышы | Ел | 1 гыйнвардан 30 июньгә кадәр | | | 1 июльдән 31 декабрьгә кадәр | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Ике ставкалы тариф | | Бер ставкалы тариф | Ике ставкалы тариф | | Бер ставкалы тариф |
| | | | Электр челтәрләрен карап тоту ставкасы | Технологик чыгым (югалту) өчен түләү ставкасы | | Электр челтәрләрен карап тоту ставкасы | Технологик чыгым (югалту) өчен түләү ставкасы | |
| | | | сум/МВт·ай | сум/МВт·сәг | сум/кВт·сәг | сум/МВт·ай | сум/МВт·сәг | сум/кВт·сәг |
| 1 | «Энерготранзит» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте – «Челтәр компаниясе» ачык акционерлык җәмгыяте | 2019 | 620 124,79 | 175,62 | 1,90994 | 620 124,79 | 175,62 | 1,90994 |
| | | 2020 | 488 133,29 | 271,68 | 1,42979 | 488 133,29 | 271,68 | 1,42979 |
| | | 2021 | 677 998,46 | 196,51 | 2,09268 | 677 998,46 | 196,51 | 2,09268 |
| | | 2022 | 689 732,80 | 204,37 | 2,13336 | 689 732,80 | 204,37 | 2,13336 |
| | | 2023 | 701 929,70 | 212,54 | 2,17565 | 701 929,70 | 212,54 | 2,17565 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 14.12.2018 № 3-12/э карарына 3 нче кушымта (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 18.12.2019 № 3-24/э карары редакциясендә)

«Энерготранзит» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең 2019-2023 елларга кирәкле тулай керемнәре (югалтуларга түләүне исәпкә алмыйча)

| № п/п | Татарстан Республикасында челтәр оешмасының аталышы | Ел | Югалтулар өчен түләүне исәпкә алмыйча, челтәр оешмасының ЗТТ |
|---|---|---|---|
| | | | |
| 1 | «Энерготранзинт» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте | 2019 | 81 856,47 |
| | | 2020 | 84 935,19 |
| | | 2021 | 89 495,80 |
| | | 2022 | 91 044,73 |
| | | 2023 | 92 654,72 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге